КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 декабрь г.Казань № 1231

2020 – 2021 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 ел, 21 декабрь, ФЗ-178 нче һәм «Акционерлар җәмгыятьләре турында» 1995 ел, 26 декабрь, ФЗ-208 нче федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләргә Татарстан Республикасы вәкилләрен билгеләргә:

махсус хокуктан («алтын акция»дән) файдалану турында карар кабул ителгән акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына бу карарга теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә;

махсус хокуктан («алтын акция»дән) файдалану турында карар кабул ителгән акционерлар җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә бу карарга теркәлгән 2 нче кушымта нигезендә;

акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» технополисы» инновацион индустриаль паркы – технопаркы» акционерлар җәмгыятенең директорлар советына бу карарга теркәлгән 3 нче кушымта нигезендә;

акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» технополисы» инновацион индустриаль паркы – технопаркы» акционерлар җәмгыятенең ревизия комиссиясенә бу карарга теркәлгән 4 нче кушымта нигезендә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеген;

акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең ревизия комиссияләренә тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеген;

акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан тәкъдим итү һәм билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеген.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турындагы хәбәрнамәләрне бу карарга теркәлгән кушымталарда һәм исемлекләрдә күрсәтелгән акционерлар җәмгыятьләренә «Акционерлар җәмгыятьләре турында» 1995 елның 26 декабрендәге ФЗ-208 номерлы Федераль закон белән билгеләнгән вакытларда җибәрергә.

4. 2020 елда бу карар белән расланган исемлекләрдә һәм аңа теркәлгән кушымталарда күрсәтелгән акционерлар җәмгыятьләрендә акционерларның еллык гомуми җыелышларын үткәргәннән соң һәм идарә һәм тикшерү органнарының яңа составын формалаштырганнан соң түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип санарга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2020 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1275 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 – 2020 елларга Татарстан Республикасы акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларына һәм ревизия комиссияләренә Татарстан Республикасы вәкилләрен тәкъдим итү һәм билгеләү турында» 2018 ел, 29 декабрь, 1275 нче карары белән расланган акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советына Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан тәкъдим итү һәм билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 16 декабрь, 1150 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карарына 1 нче кушымта

Махсус хокуктан («алтын акция»дән) файдалану турында
карар кабул ителгән акционерлар җәмгыятьләренең директорлар советларындагы
Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Казан оптика-механика заводы» акционерлар җәмгыяте

Миңгалиев Илдар Равил улы – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары.

2. «Түбән Кама техник углерод заводы» акционерлар җәмгыяте

Савельчев Алексей Петрович – Татарстан Республикасы сәүдә һәм сәнәгать министры урынбасары.

3. «Радиоприбор» акционерлар җәмгыяте

Миңгалиев Илдар Равил улы – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары.

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карарына 2 нче кушымта

Махсус хокуктан («алтын акция»дән) файдалану турында карар кабул ителгән акционерлар җәмгыятьләренең ревизия комиссияләрендәге Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Казан оптика-механика заводы» акционерлар җәмгыяте

Степанов Владимир Николаевич – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының оборона комплексы бүлеге башлыгы.

2. «Түбән Кама техник углерод заводы» акционерлар җәмгыяте

Рәхимҗанова Лилия Рафаэль кызы – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының нефть чыгару һәм нефть эшкәртү бүлеге башлыгы.

3. «Радиоприбор» акционерлар җәмгыяте

Камалова Гөлнара Марсель кызы – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының оборона комплексы бүлеге төп киңәшчесе.

4. «Казан вертолет заводы» гавами акционерлар җәмгыяте

Степанов Владимир Николаевич – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының оборона комплексы бүлеге башлыгы.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карарына 3 нче кушымта

Акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган «Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» технополисы» инновацион индустриаль паркы – технопаркы» ачык акционерлар җәмгыятенең директорлар советына билгеләү өчен Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

Адиев Эльдар Рәшит улы – Татарстан Республикасы Премьер-министрының нефть, газ һәм химия комплексы мәсьәләләре буенча ярдәмчесе;

Сибгатуллин Рөстәм Рәфкать улы – Татарстан Республикасы икътисад министрының беренче урынбасары – Эшмәкәрлекне һәм көндәшлекне үстерү департаменты директоры;

Галиев Инсаф Мөшәррәф улы – Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары;

Миңнуллин Марсель Гомәр улы – Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының хосусыйлаштыру һәм стратегик планлаштыру бүлеге башлыгы.

___

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карарына 4 нче кушымта

Акцияләренең 100 проценты Татарстан Республикасы милкендә булган
«Югары технологияләр өлкәсендәге «Химград» технополисы»
инновацион индустриаль паркы – технопаркы» ачык акционерлар җәмгыятенең
ревизия комиссиясенә билгеләү өчен
Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

Минсадыйров Ирек Илдар улы – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының нефть, газ һәм химия комплексын һәм ягулык-энергетика комплексы иминлеген үстерүне яраштыру бүлеге башлыгы;

Ибраһимов Марс Нурислам улы – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментындагы төбәк тикшерүендә тоту бүлеге башлыгы урынбасары.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карары белән расланды

Акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре
Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең
директорлар советларына тәкъдим итү өчен
Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

«Содружество» акционерлар җәмгыяте

Сафин Ленар Ринат улы – Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры;

Сибгатуллин Илдар Нурзада улы – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы.

___________________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карары белән расланды

Акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре
Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең
ревизия комиссияләренә тәкъдим итү өчен
Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

«Содружество» акционерлар җәмгыяте

Нурмөхәммәтов Илнур Фәгыйль улы – Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының стратегик үсеш идарәсе башлыгы.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 28 декабрь, 1231 нче
карары белән расланды

Акцияләре, устав капиталларындагы өлешләре
Татарстан Республикасы милкендә булган акционерлар җәмгыятьләренең
директорлар советына Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт
мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан тәкъдим итү һәм билгеләү өчен
Татарстан Республикасы вәкилләре исемлеге

1. «Татарстан Республикасының экспорт корпорациясе» акционерлар җәмгыяте

Миңнуллина Талия Илгиз кызы – Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе.

2. «Урман транспорт компаниясе» акционерлар җәмгыяте

Кузюров Равил Әфраим улы – Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры.

3. «Медицина фәне үзәге» медицина симуляторларының төбәк инжиниринг үзәге» акционерлар җәмгыяте

Садыйков Марат Наил улы – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры.

4. «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыяте

Габделганиев Фәрид Солтан улы – Татарстан Республикасы икътисад министры;

Миңнуллина Талия Илгиз кызы – Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе.

5. «Казан Арена» акционерлар җәмгыяте

Фәттахов Дамир Илдус улы – Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры;

Леонов Владимир Александрович – Татарстан Республикасы спорт министры.

6. «Иннополис» махсус икътисадый зонасы» акционерлар җәмгыяте

Габделганиев Фәрид Солтан улы – Татарстан Республикасы икътисад министры;

Миңнуллина Талия Илгиз кызы – Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе.

7. «Татарстан проектлары» акционерлар җәмгыяте

Миңнуллина Талия Илгиз кызы – Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе.

8. «ОЛ СИЗОНС ОТЕЛЬ МЕНЕДЖМЕНТ» акционерлар җәмгыяте

Иванов Сергей Евгеньевич – Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе.

9. «Татарстан Республикасының Дәүләт заказлары буенча агентлыгы» акционерлар җәмгыяте

Габделганиев Фәрид Солтан улы – Татарстан Республикасы икътисад министры.

---